**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Шешминка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Шешминка авыл җирлегенең Шешминка Крепосте торак пунктында

**28 октябрь 2025 ел** **№ 8**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлегенең Шешминка Крепосте торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елда Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлегенең Шешминка Крепосте торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге кешеләрдән, күпбалалы аналардан, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш

2. Алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- Шешминка Крепосте торак пунктында **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту), ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу, агач кисү, хезмәт өчен түләү, кирәкле кораллар, материаллар сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен махсус техника яллау;

- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Шешминка Крепосте торак пунктында урамнарны яктырту яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

- **коймаларны ремонтлау, кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (койма кору (ремонтлау), урналар кую, агачларны кисү, корыган агачлардан чистарту, инвентарь сатып алу, керү юлларын, юлларны төзекләндерү) Шешминка Крепосте торак пунктында югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу

**3. 2024 елда гражданнарның үзара салымыннан файдаланылмаган 300 000 сум акчаны** түбәндәге эшләрне башкару буенча **җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:**

- Шешминка Крепосте торак пунктында **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту), ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу, агачларны кисү, балалар өчен ишегалды мәйданчыгын киртәләү урнаштыру, хезмәт өчен түләү, кирәкле кораллар, материаллар сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен махсус техника яллау (хезмәт күрсәтүләр);

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Шешминка авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.В.Сидоров